**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"25" ноябрь 2020 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күңгәр торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылы территориясендә 2021 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күңгәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- Мәчет бинасыннан алып К. Маркс һәм Ленин урамнары чатына кадәр юлдагы барлыкка килгән чокырларга вак таш җәю, транспорт хезмәтләре өчен түләү;

- Ленин урамыннан зиратка кадәрге арага вак таш җәеп юл салу, машиналар кую өчен мәйданчык урнаштыру, транспорт хезмәтләре өчен түләү;

2. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

- лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу,урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- Ленин урамы буенча 28 - нче номерлы йорт янында елга аша салынган җәяүлеләр күперен ремонтлау, материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү;

- Иске хастаханә бинасын сүтү (калдыкларны утильләштерү, транспорт хезмәтләре һәм башкарган хезмәтләр өчен түләү);

- авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү.

4. Күңгәр авылында су чыгару башнясын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күңгәр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Салахов И.И..